ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИ-
ЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 18** **04 август 2025 ел**

Сайлау участоклары территориясендә басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү һәм аларны җиһазлау турында

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ санлы 64 маддәсендәге 8 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2025 елның 24 июлендәге «2025 елның 14 сентябрендә Татарстан Республикасы башлыгын (Рәисен) сайлауларда кандидатларның сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында»гы 99/737 санлы карары белән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы башлыгын (рәисен) сайлаулар уздырганда басма сайлау алды агитация материалларын Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә, әлеге карарга кушымта нигезендә урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирергә.

2. Махсус урыннар бүлеп биргәндә түбәндәгеләргә игътибар итәргә:

- сайлаучыларга урнаштырылган мәгълүмат белән танышу һәм аларга бару өчен уңайлы булуын;
- теркәлгән кандидатларның агитация материалларын урнаштыру өчен җитәрлек мәйдан булуны;
- басма агитация материалларын урнаштыру өчен бертигез мәйдан булуны;
- сайлау комиссияләренең, сайлау берләшмәләренең мәгълүмати материалларын урнаштыру өчен җитәрлек мәйдан булуны.

3. Басма агитация материалларын биналарда, корылмаларда һәм башка объектларда урнаштыру шартлары турындагы мәсьәләне килештерергә.

4. Махсус урыннарны һәм аларга якын территорияләрне санитар тотуны тәэмин итәргә.

5. Махсус урыннарның урнашу урыны турында мәгълүматны территория сайлау комиссиясенә тапшырырга..

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктлары территориясендә түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Кәрәкәшле авылы, М.Зәкиев урамы, 47 йорт, Кәрәкәшле авылы, М.Зәкиев урамы, 19 йорт (Кәрәкәшле авыл мәдәният йорты); Салкын-Чишмә авылы, Фрунзе урамы, 4а йорт (Салкын-Чишмә авыл клубы); Урал авылы, Урал урамы, 3а йорт; Ак-Чишмә авылы, 24 санлы йорт янында һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге электрон адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

7. Әлеге карар имзаланганнан соң үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Вакытлыча Кәрәкәшле авыл җирлеге
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы: Э.Ф.Исхакова

2025 елның 4 августындагы
18 санлы карарына кушымта

**Урнашу урыннарын күрсәтеп, басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру урыннары**

**2805 санлы сайлау участогы**

**Басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру урыннары:**

1. Кәрәкәшле авылы, Көчле-елга урамы, 13 йорт («Чулпан» кибете бинасы)
2. Кәрәкәшле авылы, Мирфатыйх Зәкиев урамы, 42 йорт («Авокадо» кибете бинасы)
3. Кәрәкәшле авылы, Мирфатыйх Зәкиев урамы, 23А йорт (“Нурлы” кибете бинасы)
4. Салкын-Чишмә авылы, Фрунзе урамы, 22А йорт (Ютазы кулланучылар җәмгыятенең элеккеге кибет бинасы)
5. Ак-Чишмә авылы, Ак-Чишмә урамы, 16 йорт (Ширмедова М.Т.ның йорт коймасында (килешү буенча)
6. Урал бистәсе, Урал урамы, 3А йорт (район кулланучылар җәмгыяте кибете бинасы)
7. Урал бистәсе, Көнчыгыш урамы, 1В йорт («Нәбиуллин» КФХ механизаторлар йорты)